| СОВЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 13 августы Әгерҗе шәһәре 39-5

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауда кичектергесез ихтыяҗ туганда җирле бюджет акчасы хисабына кире кайтарылу һәм (яки) кире кайтарылмау нигезендә өстәмә ярдәм күрсәтү тәртибе һәм очраклары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

2017 елның 20 декабреннән "Россия Федерациясе Торак кодексына һәм "Россия Федерациясендә Торак фондын хосусыйлаштыру турында" Россия Федерациясе Законының 16 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында" 399-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 28 декабреннән 33-5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауда кичектергесез ихтыяҗ туганда җирле бюджет акчасы хисабына кире кайтару һәм (яки) кире кайтарылмау нигезендә өстәмә ярдәм күрсәтү очраклары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 10 пунктның 6 абзацын «субсидия алучыларның финанс чыгымнарын тәэмин итүгә субсидияләр бирү турында килешүләр буенча йөкләмәләрен үтәү максатында төзелгән килешүләр буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булган затларның һәм субсидияләр алучыларның ризалыгы» дигән яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының сәнәгать, төзелеш, транспорт, элемтә һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе В. В. МАКАРОВ